ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2017 Казан ш. № 5-13/тэ

«Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2018 елларга «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 05.11.2015 № 5-17/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел буенча үзгәрешләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018 елга «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан, 2018 елга җайга салынулы оешманың планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2016-2018 елларга «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында» 05.11.2015 № 5-17/тэ карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча

дәүләт комитетының 30.11.2016 № 5-14/тэ карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, шушы карар кушымтасына туры китереп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2017 № 5-13/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
05.11.2015 № 5-17/тэ карарына
1 кушымта

## «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә 2016-2018 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салынучы оешманың аталышы | Тариф төре | Ел | Җылыйөрткеч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Су | Пар |
| | Казан шәһәре | | | | |
| 1 | «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | |
| | | бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 63,81 | - |
| | | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 65,32 | - |
| | | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 61,01 | - |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 61,98 | - |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 61,98 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 65,35 | -» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге